# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Әҗиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2024 елның 17 ноябре** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы Федераль законның33-ФЗ номерлы 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 17 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Әҗиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән һәм мобилизацияләнгән кешенең гаиләсеннән тыш, 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә Сез ризамы:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру);

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенына 42 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 27 кеше кертелде, бу 64,2% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 27 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Әҗиле авылында гражданнар җыены узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. « Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Татар Әҗиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән һәм мобилизацияләнгән кешенең гаиләсеннән тыш, 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә Сез ризамы:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Рус Әҗиле авыл җирлеге Татар Әҗиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән , I группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән һәм мобилизацияләнгән кешенең гаиләсеннән тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

4. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын

территорияләрне төзекләндерү (смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру);

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ш.Хаялиев